КҮПНЕ КӨТКӘНДӘ

Быелгы уңыш өметне акладымы?

> 2

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

«Подъезд янында ирләр гәпләшеп тора. Алар янына килеп җитүгә...»

> 3



ТЕЛӘК КИРӘК!

Яңа Мәрҗани һәм Барудиларны укыта торган мәдрәсәгә ничек булышырга?

> 3

ГАИЛӘ КӨЧЕ

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 137 (29104) | Чәршәмбе | 20 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КОЯШ КЕСӘНЕ ТИШМИ

Эльвира ВӘЛИЕВА

Көн кадагында

Көннәр суытканны көтәсе юк. Татарстанның унөч районында җылылык бирү сезоны башланган инде. Бу хакта төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин әйтте. Ул, салкыннар башлангач, коммуналь хезмәтләр өчен түләү артачагын да искә төшерде. Кыш кесәгә сукмасмы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Республиканың ТКХ объектлары җылылык бирү сезонына 99,9 процентка әзер. Бу хакта Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта хәбәр иттеләр. Министр Марат Айзатуллин сүзләренә караганда, җылылык бирүгә әзерлек коммуналь инфраструктураны яңарту федераль программасы кысасында алып барыла.

– Быел Әгерҗе, Зәй, шулай ук Казан һәм Чаллыдагы җылылык бирү һәм кайнар су белән тәэмин итү челтәрләрендә 27 чара тәгаенләштерелгән, – диде министр.

Сүз уңаеннан, быелның язында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә узган киңәшмәләрнең берсендә Әгерҗедә коммуналь инфраструктураның хәленә аерым тукталдылар. Мактап түгел. Ул вакытта Рөстәм Миңнеханов «Татэнерго» оешмасы генераль директоры Рәүзил Хаҗиевка якташларына ярдәм итәргә кирәклеген әйтте. Соңгы мәгълүматларга караганда, районда әлеге тармакта зур ремонт, яңарту эшләре башкарганнар. Әгерҗе – быелгы җылылык бирү сезонын инде башлап өлгергән унөч районның берсе.

– Төрле имеш-мимешләргә дә карамастан, Зәй ГРЭСы да җылылык бирү сезонына тулысынча әзер, – дип белдерде Хөкүмәт йортында узган чарада Рәүзил Хаҗиев.

Билгеле булганча, җылылык бирү сезоны урамдагы һава температурасы биш көн дәвамында тәүлегенә уртача 8 градус җылыдан түбән торса башланырга тиеш. Дөрес, әлегә көз җәйдән кимен куймый. Бу атнада, мәсәлән, республикада урыны белән 25 градуска кадәр җылы булырга мөмкин, дип фаразлый синоптиклар. Төнлә исә температура 8–10 градус җылы булачак, дип көтелә. Ә тәүлеклек уртача температураны билгеләү өчен көндезге һәм төнге күрсәткечләрне кушып, шуларны икегә бүләргә кирәк. Тик исәп-хисап белән баш катырырга ашыкмагыз, торбаларны салкыннарны башлануын көтеп тормыйча да җылыта башларга мөмкиннәр.

– Муниципаль берәмлекләр үзләре, һава температурасына карамастан, җылылык бирү сезонын башлау турында карар кабул итә ала. Иң беренче чиратта балалар бакчалары, мәктәп, хастаханәләр кебек социаль объектлар тәэмин ителәчәк. Бүген республиканың унөч районында җылылык бирү сезоны башланды, – диде Марат Айзатуллин.

Бер рәхәтнең бер кыены була, дигәндәй, торбалар кайнарлану белән, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазьләре дә кыйммәтләнәчәк. Бу хакта министр да әйтте.

– Җылылык сентябрь аенда бирелә башлаган очракта, октябрьдә алган «счет-фактура» кәгазендә җылылык өчен түләү турында аерым пункт барлыкка киләчәк. Узган айда тотылган энергия өчен исәп-хисап ясалачак. Гомуми йорт исәпләгечләре булмаган торакта яшәүчеләр исә җылылык бирү сезоны дәвам иткән сигез айны исәпкә алып, алдан билгеләнгән нормативлар буенча түләячәк, – диде Марат Айзатуллин.

Министр мичкә күбрәк яккан саен, өстәп түләргә туры килүен дә искә төшерде.

– Җылылык энергиясенә бәйле чыгымнар һава температурасына турыдан-туры бәйле. Кагыйдә буларак, җылылык өчен иң зур түләүләр гыйнвар – февраль айларында килә, – диде ул.

Дөрес, министр Татарстанда яшәүчеләрне алдан ук тынычландырып та куйды:

– Быелның 1 июленнән кулланучылар өчен коммуналь хезмәтләр, шул исәптән җылылык өчен тарифлар үзгәрмәде. Чираттагы индексацияләү 2024 елның 1 июленнән генә булачак, – диде Марат Айзатуллин.

Быел җылылык бирү сезоны башланган районнар

Әгерҗе ▶ Аксубай ▶ Апас ▶ Арча ▶ Баулы ▶ Буа ▶ Югары Ослан ▶ Биектау ▶ Кама Тамагы ▶ Мөслим ▶ Яңа Чишмә ▶ Чирмешән ▶ Ютазы

Хәтерләсәгез, соңгы тапкыр коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр ил күләмендә узган елның 1 декабрендә артты. Россия Хөкүмәте карары нигезендә былтыр тарифлар бер ел эчендә ике тапкыр (ут-су, җылылыкка бәяләр гадәттә елга бер тапкыр үсә) күтәрелде. Алдагы ел белән чагыштырганда, республиканың кайбер шәһәр һәм районнарында яшәүчеләрнең ут һәм суга киткән чыгымнары 20 процентка кадәр артты. Шуңа күрә дә былтыр кыш уртасында килеп төшкән коммуналь түләү кәгазьләре халык арасында зур шау-шу уятты. Рөстәм Миңнеханов аңлату эшләре оештырырга да кушты хәтта. Быел исә коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр былтыргыдан да зуррак булмаячак, дип өметләнәсе генә кала. Бөтендөнья метеорология оешмасы белгечләре Россиядә быелгы кышны гадәттән тыш җылы булачак дип фаразлаган инде әнә. Әйтүләренә караганда, кышның беренче ике ае нормадан 4–5 градуска җылырак булачак. Аның каравы күп итеп кар һәм бозлы яңгырлар вәгъдә иткәннәр. Коммуналь хезмәткәрләр генә чыдасын.

Кушылу көне

Россия Дәүләт Думасы 30 сентябрьне Донецк, Луганск халык республикаларының, Запорожье һәм Херсон өлкәләренең Россиягә кушылу көне буларак билгеләү турында закон проектын беренче укылышта кабул иткән. Президент Владимир Путин әлеге документны Дәүләт Думасына 12 сентябрьдә керткән иде.

Исегезгә төшерәбез: узган елның 23–27 сентябрендә яңа төбәкләрне Россия составына кертү мәсьәләсе буенча референдумнар узды. Запорожье өлкәсендә – сайлаучыларның 93,11 проценты, Херсон өлкәсендә – 87,05, Луганск Халык Республикасында – 98,42, Донецк Халык Республикасында сайлаучыларның 99,23 проценты Россиягә керүне хуплап тавыш бирде. Ә инде 30 сентябрьдә Мәскәү Кремлендә яңа территорияләрне Россия составына кертү турында килешүләрне имзалау тантанасы узды. Документларны Владимир Путин һәм кушылган төбәкләр башлыклары имзалады.

Кирәкле кешеләр

Татарстан Хөкүмәте республика оешмалары өчен кирәкле һөнәрләр исемлегенә яңаларын өстәгән. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән боерыкка кул куйган.

Шулай итеп, яңартылган исемлеккә химик анализ лаборанты, тимер һәм эретмәләр коючы, буяучы, кран машинисты, цех механигы, контроль-үлчәү приборларын көйләүче, автомат һәм ярымавтомат станоклар операторы, тимер эретүче, бораулаучы, слесарь, токарь кебек һөнәрләр кертелгән.

Ярышу өчен тырышу

Киләсе елда Парижда узачак Олимпия уеннарына Россия спортчылары кертелсә, бездән анда 180 кеше чыгыш ясый алачак. Россия спорт министры Олег Матыцин әйтүенчә, спортчыларның квалификациясе мөмкинлекләреннән чыгып билгеләнгән сан бу. «Командаларның катнаша алмаячагын аңлыйбыз. Бу – максималь сан. Гәрчә хәлләр көн саен үзгәреп торса да. Тик, кызганычка, яхшы якка түгелдер, мөгаен», – дигән министр.

Әлегә Халыкара Олимпия комитеты Россия, Белоруссия спортчыларын Парижда узачак уеннарга кертү турында карар чыгармады. Оешманың гамәлдәге кагыйдәләре буенча, ике ил спортчылары халыкара турнирларда нейтраль статуста һәм бары шәхси ярышларда гына чыгыш ясый ала.

Яңалык

Кәгазьдәгесе югалмый

Россия Президенты Владимир Путин цифрлы паспорт турында указны имзалады. Шәхесне раслау хәзер тагын да җиңеләя: интернет һәм телефоның гына булсын!

ru.freepik.com

Дәүләт башлыгы указында язылганча, Россиядә яшәүчеләр мобиль кушымта (бу очракта «Госуслуги») кулланып, таләп ителгән җирдә үзенең шәхесен раслата ала. Әмма әлеге «таләп ителгән» урыннарны ил Хөкүмәте үзе билгели. Владимир Путин өч ай эчендә мобиль кушымта аша күрсәтелергә мөмкин булган мәгълүматлар тупланган документлар исемлеген билгеләргә кушты. Аны куллану һәм реестрны алып бару тәртибен шулай ук Министрлар Кабинеты расларга тиеш. Шуңа күрә электрон паспортны ничек кулланасы әлегә билгеле түгел. Гади итеп әйткәндә, цифрлы паспорт үз эченә паспортны гына түгел, башка төр документларны (әйтик, машина йөртү таныклыгы) да алачак.

Сан

2020 елда Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре электрон паспорт турында сораштыру үткәргән иде. Сораштыруда катнашучыларның 9 проценты, аның уңай яклары турында сөйләгәндә, паспортны урлап яисә югалтып булмый, дип белдергән. 6 проценты исә, кәгазь паспорт кебек, үзең белән йөртергә кирәк түгел, дигән. 4 проценты, андый паспорт пычранмый, ертылмый, дип әйткән. Шулай ук илдә яшәүчеләрнең һәр дүртенчесе, андый паспортның бернинди дә өстенлеге юк, дигән фикердә.

Россиянең Цифрлаштыру министрлыгы искәрткәнчә, электрон паспорт кәгазь документны алмаштырмаячак. Теләге булган кешеләр гадәтләнгән кәгазь паспорт белән йөри алачак. Электрон паспортны рәсмиләштерү ирекле.

Министрлык мондый паспортның якынча ничек эшләвен дә аңлаткан иде. Барысы да бик гади: телефонга паспортның фотосурәтләрен кертә, соңрак QR-код чыкканын көтәсе. Шушы кодны паспорт урынына кулланырга мөмкин дә инде.

Шунысы да бар: кайбер белгечләр, цифрлы паспортларның гамәлгә керүе базадан шәхси мәгълүматны урлау очраклары артуга китерергә мөмкин, ди.

Сүз уңаеннан, электрон паспорт төшенчәсе яңалык түгел. Казахстанда, мәсәлән, шәхесне раслаучы махсус чип-таныклык 2008 елда ук кертелгән иде. Эстониядә ID-карта дигән электрон документ гамәлдә. Германиядә дә шундый ук ID-карта бирәләр.

Сүзгә-сүз



Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Россия икътисадын торгызу этабы тәмамланды дип әйтергә була. Без моңарчы күрелмәгән тышкы басымга, санкцияләр һөҗүменә каршы тора алдык. Россиянең тулай эчке продукты 2021 елгы күрсәткеченә чыкты. Безгә алга таба да тотрыклы һәм озак вакытлы үсеш өчен шартлар тудыру мөһим.

(Федераль бюджет формалаштыру мәсьәләләре буенча киңәшмәдән)

РОССИЯДӘ – КӨЗГЕ ЯЛ

SuperJob хезмәте Россиядә яшәүчеләр арасында көзге ял өчен иң популяр төбәк һәм шәһәрләрне ачыклаган.

1. >> Санкт-Петербург
2. >> Краснодар крае
3. >> Төньяк Кавказ
4. >> Казан
5. >> Алтай
6. >> Кырым

Муллыктан өлеш

Татарстанда гошер сәдакасын җыю дәвам итә. Билгеле булганча, Татарстан Диния нәзарәте гошер көне дип агымдагы елның 23 сентябрен игълан итте. Гошер көне Татарстанда барлык мөхтәсибәтләрдә үзәкләштерелгән рәвештә 2017 елдан бирле үткәрелә. Һәр елдагыча, мөхтәсибәтләрдәге мәчетләр гошер сәдакасы итеп җиләк-җимеш һәм яшелчәләр кабул итә. Соңрак азык-төлекне аз керемле, мохтаҗ кешеләргә тапшыру оештырылачак. Казанда гошерне нәзарәт карамагындагы «Зәкят» хәйрия фонды кабул итә һәм тарата.

Саннарга күз салсак, 2017 елда – 160 тонна, 2018 елда – 600 тонна, 2019 елда – 1109,5, 2020 елда – 1000 тоннага якын, 2021 елда – 577,33 тонна, 2022 елда 1377,34 тонна гошер сәдакасы җыеп таратылган.

dumrt.ru



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

НЕФТЬ БӘЯСЕ ҮСӘ, АШЛЫКНЫКЫ ТӨШӘ...

Дөнья базарларыннан каршылыклы хәбәрләр килә. Бердән, глобаль рәвештә җитештерүнең кимүе көтелә, чөнки финанс кризисы беркая да китмәде һәм процент капиталына корылган капитализмны җирләмичә китмәячәк тә.

Атна башында Кытайның China Evergrande Group төзелеш гигантының акцияләре 25 процентка арзанайды. Кыйммәтле кәгазьләрнең чүплеккә очуы компаниянең капитал белән идарә итү тармагы җитәкчесен полиция кулга алганнан соң башланды. Американың дәүләт әҗәте рекордлы темплар белән үсә. Европада да кризис билгеләре торган саен арта. Әйтик, банкротлыкка чыгучы компанияләр саны рекордлы күрсәткечтә. Мондый шартларда гадәттә «кара алтын» бәясе түбәнгә китә. Ләкин быел җир мае арзанаерга уйламый да. Киресенчә, кайбер базарларда баррель инде 100 долларга сатыла, диләр. Qua Iboe маркалы Нигерия нефте 100 долларлык чикне узган, Малайзиянең Tapis маркасы 101,30 долларга җиткән. Шведларның SEB банкы аналитигы Бьярне Шилдроп: «Согуд Гәрәбстаны һәм Россия нефть базарын нык контрольдә тота», – ди һәм Брент маркасының да 100 доллардан узып китәчәген фаразлый. Башка белгечләр дә аның сүзен куәтли. Көнбатышта дизель ягулыгы дефицитта. Вазгыять Россия өчен бик уңайлы, әмма ул 2008 елгы кризисны искә төшерә. 2008 елда да көзен «кара алтын» бәяләре күккә ашты, баррель рекордлы 147 долларга кадәр үсте. Һәм көтмәгәндә барысы да әйләнеп капланды: җитештерү кискен кими башлады, чимал бәяләре чамасыз арзанайды, эшсезлек мәйданга чыкты... Ул чакта капитализм үз үлемен чамасыз акча басып һәм чикләнмәгән кредитлар өләшеп артка чигерде. Бу формула бүген эшләми. Ул базарларда инфляция биюенә китерде. Дәүләтләр валюта сугышлары һәм сәүдә сугышлары башлап җибәрде, мул итеп үзара санкцияләр өләшенде. Безне климатның глобаль үзгәрешләре һәм тотал ачлык белән куркыта башладылар.

Сәхнә артында ачлык өрәге басып торганда, базарларда ашлыкка бәяләр төшә. Евросоюз Украина ашлыгына керткән эмбаргоны үткән көннәрдә алды, әмма Польша, Словакия һәм Венгрия көнчыгыш күршеләренең ашлыгын үзләрендә сатарга рөхсәт итмиләр. Үз крестьяннарының хакларын яклыйлар. Киев моңа риза түгел. Өч илне Бөтендөнья сәүдә оешмасы хөкеменә бирде. Болгария хакимиятләре Украина ашлыгына чикләрне бикләмәделәр, әмма бу болгар фермерларының җен ачуын чыгарды. Алар гомуммилли протест акциясе башлап җибәрделәр. Ашлык җитештерүче илләрдә фермерларның хәле яхшы түгел. Бәя төшү бөлдерә. Казахстан Президенты Токаев үткән шимбәдә хөкүмәткә фермерлар һәм крестьян хуҗалыкларына финанс һәм башка төрле ярдәм оештырырга күрсәтмә бирде.

Россиядә

ЭШ КЕШЕНЕ ЭЗЛИ

Дөньякүләм җәелгән глобаль проблемалардан Россия дә читтә кала алмый, чөнки бер үк икътисад моделендә яшибез. Чимал державасы булу агымдагы вазгыятьтә безнең хәлне берникадәр җиңеләйтә, әмма махсус хәрби операция һәм санкцияләр барыбер үз эшен эшли. Кытай базарына бәйлелек үз проблемаларын тудыра. Пекин үз товарларына бәяләрне даими күтәрә, ә чималны ярты бәясенә генә ала. Кытай продукциясе сыйфаты белән мактана алмый. «Известия» хәбәр итүенчә, кытай автомобильләренә күчеп утырган россиялеләр массакүләм рәвештә аларның сыйфатыннан зарлана. Әмма беркая барып булмый, чөнки Күк асты иле терәмәсә, зур дефицит пәйда булачак.

Ашлыкка бәяләр төшү Россия фермерларын да җәфалый. Уңыш мул, әмма аны куярга урын юк. Кара диңгез аша читкә озату кыенлашты. «Ашлык килешүе» хәзер Украина өчен генә түгел, Россия өчен дә мөһим. Әмма уртак тел табу авырайды. Бөртекләргә бәя төшү темплары исә көчәя. Соңгы атнада бодайның тоннасы 425 сумга кадәр очсызланып, бәя 12,4–13,5 мең сумга гына калган.

Илдә кадрлар дефициты көчәя. Сум девальвациясе дә үз өлешен кертә. Долларга күчереп исәпләгәч, хезмәт хаклары кечерәя, мигрантлар моннан риза түгел. Хәрби сәнәгать комплексы җитештерүне кискен арттырды, күпләр хәрби заводларга эшкә күчте. Хезмәт хаклары югары, бронь да бирелә. Махсус хәрби операция төгәлләнгәннән соң, зур проблема вәгъдә итә бу. Оборона тармагын кысарга туры киләчәк. 1992 елда СССР таркалганда бер кичтек без андый вазгыятьне. Заводлар туктап, миллионнар эшсез калды. Әлегә эш кешене эзли. Уралда эшче куллар кытлыгы үзен аеруча сиздерә. Урам себерүчеләр, аш пешерүчеләр, кибет администраторлары җитешми. Табиблар белән дә шул ук хәл. Автослесарьлар, токарьлар, җыештыручылар, слесарьлар эшкә шулай ук җиңел урнаша ала.

Нефть державасы булуга карамастан, Россиядә дә мотор ягулыгы кризисы көчәя. Федераль хөкүмәт төрле чаралар күрергә тырышып карый, әмма әлегә нәтиҗәсез. Проблеманың хәл итүгә бирешми торган яклары бар.

Бу юллар язылганда, Сокольникидагы ковид госпитале эшли башлады дигән хәбәр килде. Проблемалар артык төенләнсә, ковидны ярдәмгә чакырырга туры килмәгәе.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ДУСЛАР ТӘҖРИБӘСЕ

tatarstan.ru

Шушы көннәрдә Татарстан башкаласына Үзбәкстан Премьер-министры Абдулла Арипов җитәкчелегендә делегация килеп китте. Татарстан кунакларга үзенең икътисадый һәм сәнәгый мөмкинлекләрен күрсәтте, тәҗрибә уртаклашты.

Республика Рәисе Үзбәкстан белән хезмәттәшлекне арттыру мөмкинлекләрен югары бәяләде. Сүз уңаеннан, уртак проектлар бар инде. Әйтик, Җизакта КФУ филиалы, «Чирчик», «Җизак» технопарклары эшләп килә.

Үзбәкстан вәкилләре яңа IT парк, «Школа 21» мәктәбен карады. «Алабуга» махсус икътисадый зонасын барып күрде. Мәгълүм булганча, әлеге икътисадый зонада импортны алмаштыручы 30дан артык уникаль җитештерү мәйданчыгы урнашкан. Алар үз юнәлешләре буенча алдынгы санала. «Алабуга»га кертелгән инвестицияләр күләме 163,9 млрд сумны тәшкил итә.

САН

Узган ел йомгаклары буенча Татарстан – Үзбәкстан товар әйләнеше үсеш күрсәтте һәм **290 млн** доллардан артып китте. Бу елның беренче яртысында шулай ук **30** процент үсеш күзәтелә.

Биредә 12 меңнән артык эш урыны булдырылган. Узган ел нәтиҗәләре буенча, зона резидентлары кереме 138 млрд сумга җиткән.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Үзбәкстан Премьер-министры Абдулла Арипов икътисадый зонадагы кайбер резидентлар эше белән танышты. Аерым алганда, бу – Kastamonu заводы (ламинат җитештерә, илдәге идән япмалары базарының 20 процентын били), AURUS автомобиле җитештерү заводы.

Кунаклар «Алабуга Политех» мәгариф үзәген дә карады. Монда елына 10 меңләп кеше укыту мөмкинлеге бар. Белем бирү үзәгендәге укучылар заманча җиһазларда шөгыльләнә, икътисадый зона заводларының иң яхшы инженерларыннан күнекмәләр ала. Моңа өстәп компанияләрдә стажировка да уза.

– Монда укучылар, класста утырып, укып кына калмый, эшли дә, яхшы хезмәт хакы да ала, – дип искәртте Рәис. – Бу – үз эшләрен яхшы белгән белгечләр.

ШИФАЛЫ ҖАВАП

Табибка язылу, кирәкле даруны таба алмау, вакцинация ясау урыннары... Республика халкын әнә шул мәсьәләләргә кагылышлы сораулар борчый икән. Бөтендөнья авырулар куркынычсызлыгын яклау көне уңаеннан белгечләр Татарстан халкыннан килгән иң актуаль сорауларны барлады.

Росздравнадзор идарәсенең Татарстандагы бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүчеләр саны кимегән. Идарәнең бүлек мөдире Фәридә Дучицкая сүзләренә караганда, быел 9 айда аларга 1052 мөрәҗәгать килеп ирешкән. Узган елгыдан 14 процентка кимрәк икән. Идарәгә килеп ирешкән мөрәҗәгатьләрнең күбесе медицина ярдәменең сыйфаты һәм куркынычсызлыгына (53 проценты), дарулар белән тәэмин ителешкә (32 процент) кагыла.

– Медицина ярдәме сыйфаты дигәндә, бу уңайдан килеп ирешкән сорауларның күбесе медицина хезмәте күрсәтүне оештыруга бәйле. Шәхси оешмаларга бәйле мөрәҗәгатьләр дә шактый. Ел башыннан бирле идарәгә шундый 204 сорау килде. Табибларга язылу, аларның үз-үзләрен тотышына кагылышлы сорауларына ачыклык кертергә теләүчеләр дә шактый. 492 мөрәҗәгать буенча чаралар күрелде, 173е ялган мәгълүмат булып чыкты, – ди Фәридә Дучицкая.

Табибка язылу күпләрнең үзәгенә үткән мәсьәлә булса да, соңгы арада республика халкы белгечләргә язылып булмаудан азрак зарлана башлаган. Һәрхәлдә, Росздравнадзор идарәсендә шулай дип ышандыралар.

Сентябрь башында Татарстанның Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге каршында бердәм колл-үзәк (телефон номеры: (843) 221-16-50) пәйда булды. Сәламәтлек саклауга бәйле сорауларны анда да кабул итәләр.

– Медицина хезмәтләре сыйфатын яхшырту, кеше тиешле хезмәтне вакытында алсын өчен эшләнде бу. Колл-үзәктә бүлек мөдире, табиб-статистик, һәркайсының үз операторлар төркеме булган өч төп белгеч бар. Моннан тыш безнең Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы кебек эре шәһәрләрдә дә белгечләребез бар. Алар өч сменада эшли. Колл-үзәк тәүлек әйләнәсе хезмәт күрсәтә, – ди Үзәк җитәкчесе Аида Коростелева. – Үзәктәге белгечләр кешегә барлык кирәкле мәгълүматны бирергә, табибка язылырга, өйгә табиб чакыртырга ярдәм итәргә тиеш. Колл-үзәк белгечләре мөрәҗәгатьне кабул итеп, теркәп кенә калмый, аларның ахыргача үтәлешен дә контрольдә тота.

Колл-үзәккә тәүлегенә 100дән артык шалтырату килеп ирешә икән. Вируслар котырган чорга аяк бастык. Шуңа күрә узган атнаның җомгасыннан башлап колл-үзәккә ярдәм сорап шалтыратучылар саны да арткан.

– Якын арада кешенең табибка язылганлыгын раслаучы чат-бот барлыкка киләчәк. Юкса табибка язылган кешеләрнең 20 проценты чынлыкта анда бармый, – ди үзәк җитәкчесе.

Колл-үзәккә медицина тармагына бәйле булган башка оешмаларны да тоташтырмакчылар. Әле күптән түгел генә анда Сәламәтлек саклау министрлыгының «кайнар элемтә»сен тоташтырганнар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЛАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү турында

Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимен карап, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә бирергә:

Әхмәтова Дания Заһри кызына – педагогика фәннәре докторы, «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең өзлексез белем бирү буенча проректоры, педагогик инновацияләр һәм инклюзив белем бирү фәнни-тикшеренү институты директорына;

Гаврилова Ольга Викторовнага – Казан шәһәре Совет районының «141 номерлы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең инглиз теле укытучысына.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 19 сентябрь
№ 652

2023 елда Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү турында

Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне бирү комитеты тәкъдимен карап, **карар бирәм:**

1. 2023 елда Инженерлык фәннәре өлкәсендә күренекле өлеш керткән өчен А.Н. Туполев исемендәге халыкара премияне Рудской Андрей Ивановичка – «Бөек Петр исемендәге Санкт-Петербург политехника университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры, Россия фәннәр академиясе академигына бирергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2023 ел, 19 сентябрь
№ 653

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты **Власов** Валерий Александрович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

Гозерләр үтәләчәк

Төрле стильдәге карате белән шөгыльләнүчеләргә – спорт залы, 86 яшьлек ялгыз пенсионерга йортын төзекләндерүгә ярдәм кирәк. Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия»нең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин партия Рәисе Дмитрий Медведевның Төбәк иҗтимагый кабул итү бүлегендә халыкның гозерен тыңлады.

«Россиянең төрле стильдәге карате студентлар федерациясе» иҗтимагый оешмасы президенты Борис Белов әйтүенчә, аларга күнегүләр үткәрү өчен спорт залы кирәк. «Ноябрь аенда Орел шәһәрендә әлеге спорт төре буенча халыкара ярышлар уздырылачак, – диде ул. – Ләкин, зал булмау сәбәпле, җыелма команданың ярышларга тиешенчә әзерләнү мөмкинлеге юк». Фәрит Мөхәммәтшин Спорт министрлыгына бу мәсьәләне хәл итү бурычын куйды.

Казанның Идел буе районында яшәүче 86 яшьлек Александра Синицына исә үзе яши торган йортка һәм бүлмәсенә капиталь төзекләндерү уздыруны сорап килгән. Йортны 1960 елда ук төзегәннәр. Хәзерге вакытта Александра Николаевна ялгызы яши икән. Улы Виталий 1980 елда хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булган. Мирный бистәсендәге Фестиваль урамына Виталийның исемен биргәннәр. Ә 129 нчы мәктәп музеена истәлек тактасы урнаштырганнар. Фәрит Мөхәммәтшин әлеге мәсьәләне үз контроленә алды.

КҮҢЕЛ КҮПНЕ КӨТКӘН ИДЕ

Сораштыру

Уңышны көзен барлыйлар. Амбарлар ашлыклар белән тулган, складларга күпчелек яшелчәләр кайтып урнашкан, терлекләр азыклы булган вакыт. Игенчеләр, терлекчеләр, яшелчәчеләр быелгы уңыштан канәгатьме, әллә авырлыклар күбрәк булганмы? Без шул хакта белештек.

Ильяс СӨЛӘЙМАНОВ, фермер (Аксубай районының Иске Ибрай авылы):
– Минем 200 баш савым сыерым бар. Елны, уртача килде, дип бәялим. Тик менә терлек азыгы әзерләү белән генә авырлыклар бар. Шуңа күрә бөртеклеләрнең барысын да сенажга салырга туры килде. Яңгырлар булмау сәбәпле, җәй башында терлек азыгын җитәрлек күләмдә әзерләп булмады. Башка елларны үземнән арткан ашлыкны бераз саткан булсам, быел хәтта үземә сатып алырга туры килде. Арпаны 8 сумга бирделәр. Моннан тыш, үземнең бер еллык ашлык запасы бар иде. Кышын, язын, җәен сөт бәяләре төшеп, бик нык авырлык китерде. 18–19 сумга төшеп беткән иде бит. Әле ярый бер ай элек 26 сумга күтәрелде. Тик хәзер сыерларның сөте кимеде. Азык булмагач, күп биреп булмый. Менә хәзер жмых (шикәр чөгендере чүбе) алырга кирәк, ләкин анысы кыйммәт әле. Алып булмый. Азык өстәмәләре дә кыйбатка чыга. Сөт хаклары тагын күтәрелер, диләр, бар өмет шунда инде. Җәен сөткә бәя булмагач, җыйган акчаны кредитка салдык та запаслар бетте.

Наилә ӘХМӘДИЕВА, фермер (Апас районының Дәвеш авылы):
– Үзебезнең участокта сигезәр гектар бәрәңге һәм суган утырттык. Безнең өчен бу сезон бик уңышлы булмады. Бездә бәрәңгене су сиптермичә үстереп булмый, чөнки җәй елдан-ел кызурак килә. Бәрәңгене танышлар, социаль челтәрләр аша тиз арада сатып бетердек. Суганны сатмыйбыз, теплицада кыякка утыртырга калдырам. Бүген безне ягулык бәяләре бик нык борчый. Җирләрне эшкәртергә, башка фермерларга көзге чәчү эшләрен дә башкарырга кирәк. Шуңа күрә авырлык бар. Безнең полосаны юкка гына «игенчелек белән шөгыльләнү өчен ышанычсыз зона» дип әйтмиләр. Сезонны башларга акча булган очракта да, отарга да, оттырырга да мөмкин. Мул уңыш алу белән генә дә түгел бит әле. Алган продукцияне уңышлы сатарга да кирәк. Мин, мәсәлән, бәрәңгене базарда сата алмадым. Чөнки мине анда белмиләр, ә менә интернет аша рәхәтләнеп урнаштырып бетердем. Ә бөртеклеләрне ничек сатарга? Узган елдан бирле ашлыкларын урнаштыра алмаучылар бар. Аларга бу хәлдән ничек чыгарга? Товар сату белән күпчелек кеше авырлык кичерәдер, дип уйлыйм. Чыгарган чыгымнарны җыеп алырга да кирәк бит әле. Бездә сыйфатлы орлык мәсьәләсе дә бар. Чит илнекеләрдән китеп, үзебездә җитештерелгән сортларны алып үстерергә кирәк. Алар бар, ләкин бу мәсьәләдә эшлисе эшләр дә күп әле. Безгә, фермерларга, яңа сорт бәрәңгеләрне үстереп, сынап карарга һәм халыкны аларга ияләштерергә кирәк булачак.

Илдар УСМАНОВ, «Агротранспорт» хуҗалыгы агрономы (Чүпрәле районы):
– Безнең өчен ел уңышлы килде. 6000 гектар чәчүлек мәйданы бар. Көзге культуралардан гектарына 60–70 центнер уңыш җыеп алуга ирештек. Язгы культуралар да, солы да яхшы уңыш бирде. Зарланырлык булмады. Ашлыкны да үзебезгә җитәрлек күләмдә әзерли алдык. Ләкин сату өчен бик арттыра алмабыз. Аның бәясе дә арзан бит. 7–8 сум тора. Менә хәзер кабаттан яңгырлар көтәбез инде. Җирләр бик каты. Сукалау өчен дә уңайсыз. Яңгырның артыгы юк. Бездә аңа һәрвакыт кытлык.

Рафак ХӘЛИУЛЛИН, Кукмара районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы:
– Без быел узган елның 70 процент уңышын җыеп алдык. Әлбәттә, тагын да зуррак нәтиҗәләргә өметләнгән идек. Без инде ашлык сата торган район түгел. Иң мөһиме – терлекләргә җитәрлек күләмдә азык әзерләү. Безнең өчен сыерларның күп сөт бирүе, аның өчен азыкның мулдан булуы кирәк. Узган елгы запаслар белән райондагы терлекләргә җитәрлек азык туплый алдык. Дөрес, төрле хуҗалыклар бар. Үләнне өч тапкыр чабып алучылары да, бер-ике кат белән чикләнүчеләре дә. Бу инде табигать шартларына гына түгел, технологияләргә дә карый. Тырышканнар, технологияне дөрес файдаланганнар уңышны яхшы алды.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТУГАН ЯК ҖЫЛЫСЫ

Ватан хакына

«Сез безгә бик кирәк!» Район җитәкчеләренең махсус хәрби операция зонасыннан ялга кайткан егетләр белән очрашуларында иң еш яңгыраган сүзләр бу. Хәрбиләрне һәм аларның якыннарын нәрсә борчый? Кәефләре ничек? Без шуларны белештек.

НУРЛАТ районы егетләре өчен дә җитәкчелек белән очрашу традициягә әйләнгән. Аның чираттагысы узган атнада булды. Чәй өстәле янындагы очрашуда катнашкан «Матрос» позывнойлы солдат, район күрсәткән ярдәмне тоябыз, ди. Бу аның икенче мәртәбә ялга кайтуы икән.

– Махсус хәрби операция зонасына китүгә, балаларым бакчага һәм төрле түгәрәкләргә бушлай йөри башлады. Сөендем, билгеле. Гомумән, якташлар ярдәмен тоябыз без. Алар җибәргән күчтәнәчләр, кирәк-яраклар да килеп җитә. Аеруча ризыклары өйгә алып кайткандай итә, – дип сөйли хәрби.

«Ингуш» позывнойлы солдатның исә күкрәгендә «Махсус хәрби операциядә катнашучы» медале ялтырый.

– Без шәһәргә кергән һәм чыккан машиналарны тикшереп торабыз. Медальне тыелган матдәләр ташучыларны тоткарлаган өчен тапшырдылар, – дип урталкашты ул.

Егетләр һәрвакыттагыча зарлануны белми. Киресенчә, «Җиңәчәкбез!» – дип, күңелләрдә өмет уяталар.

Район башлыгы Дамир Ишкинеев исә нурлатлылар арасында контракт нигезендә хезмәткә баручыларның күп булуын әйтте. Егетләргә исә тиз арада әйләнеп кайтырга теләде.

– Сез безгә бик кирәк! Үзегезне саклагыз. Без сезне бик көтәбез, – диде ул.

ЗӘЙДӘГЕ очрашуны район башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Петр Уразайкин уздырды. Беренче эш итеп, мобилизацияләнгән ирегетләргә һәм аларның гаиләләренә күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында сөйләде ул. Бу өлкәдә шактый көч куючы активистларны да игътибарсыз калдырмады.

Очрашу барышында махсус хәрби операциягә Зәйдән киткән бер егетнең «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнүе билгеле булды. Петр Уразайкин әлеге зур бүләкне хәрбинең тормыш иптәше Еленага тапшырды.

МЕНДЕЛЕЕВСК районының Татар Чаллысы авылы клубында да булды мондый очрашу. Ике атналык ялга кайткан егетләр авылдашларына махсус хәрби операция зонасындагы хәлләр, авылдан килгән хатларның, якташлары җибәргән күчтәнәчләрнең ни дәрәҗәдә мөһим булуы турында сөйләде. Балалар аларны аеруча зур игътибар белән тыңлады, сорауларына җаваплар таба алды.

Соңыннан авылдагы халык ансамбленә йөрүчеләр егетләргә үзләре үргән маскировка челтәрләрен тапшырды.

Яшел Үзән районының Әйшә авыл җирлеге башлыгы Радик Галәвиев махсус хәрби операциягә киткән. Бу турыда район хакимиятенең «Телеграм»дагы каналында хәбәр ителә.
57 яшьлек авыл җирлеге башлыгы контрактны сентябрь башында төзегән. «Ул – чын җитәкче һәм патриот. Хәрби операция зонасына барырга карар кылды, миңа үз фикерен үзе әйтте, мин аның карарын хупладым», – ди Яшел Үзән районы башлыгы Михаил Афанасьев.

zainsk-inform.ru

«Иregезгә күрсәткән ярдәмегез, аны рухландырып торуыгыз өчен бик зур рәхмәт! Ил алдындагы хәрби бурычын үтәгәндә аның өчен шуннан да мөһимрәк нәрсә юктыр», – диде Петр Уразайкин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

БӘХЕТ – БЕРДӘМЛЕКТӘ

Шәйхайдаровлар гаиләсе архивыннан

Соклану

Бәхет үз кулыбызда! Республика күләмендә узучы «Нечкәбил» бәйгесенең ярымфиналында катнашучылар әнә шулай ди. Бигредә тормышның ямен, гаиләнең кадерен белүчеләр җыелган. Йөзләреннән нур бөркелә, итәк тулы балалары, яныңдә хәлле, туганнары аларның. Матур гаиләнең ничек яшәвен, бер-береңә, туганнарыңа булган хөрмәтне бу бәйгедә күреп була.

Әлеге бәйге быел 18 нче мәртәбә уздырыла. Ярымфиналда республиканың төрле район-шәһәрләреннән килгән 30 гаилә катнашты. Әлегә финалга чыгучыларның исемнәре билгеле түгел, аларны соңрак беләчәкбез. Хикмәт нинди урын алуда да түгел. Казан сәхнәсенә чыгып баскан һәр гаилә – җиңүче! Татарстанның Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова әнә шулай ди.

– Бу – бик матур гаилә бәйрәме. Сезне Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, хатын-кыз депутатларның «Мәрхәмәт» оешмасы исеменнән сәламлим. «Нечкәбил» бәйгесе гаилә кыйммәтләре турында сөйли. Биредә гореф-гадәт, милли йолаларны онытмаучы гаиләләрне үрнәк итеп күрсәтәләр, – ди Римма Ратникова. – Хәзерге яшьләр бәби табарга ашыкмаса, монда катнашучылар күп итеп бала үстерә. Ә бит хатын-кызның матурлыгы – ана булуда. Дөрес, сәхнәгә чыгу җиңел эш түгел. Үз гаиләңне башкаларга күрсәтү тагын да катлаулы. Хатыннары янәшәсендә торган ирләргә рәхмәт. Гаиләгез өчен янып яшәүегез белән үрнәк сез!

«Нечкәбил» бәйгесен оештыручы Изольда Жуйкова да чыгышын рәхмәт сүзләреннән башлады.

– «Нечкәбил» бәйгесе Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев хәер-фатихасы белән башланды. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та ярдәм итеп тора. Быел әле Алабуга шәһәрендә бер бәйрәмдә Рөстәм Миңнеханов белән очраштык. «Фестиваль ни хәлдә?» – дип сорады. 18 ел буе алып барган эшебезгә сокланды, рәхмәтен җиткерде, – ди Изольда Жуйкова. – Бу бәйге гаиләләрне берләштерә, алардагы җылылыкны саклый, мәхәббәтне нығыта.

«Нечкәбил» бәйгесендә язмышлары «ВТ» газетасында бәян ителгән гаиләләр дә бар иде. Тукай районының Сәмәкәй авылында яшәүче Әлфирә һәм Раиф Исхаковлар үзләренең ике уллары янына ике ятим кыз баланы да сыендырган. Олы кызлары Альбинага 23 яшь икән инде.

– Ике кызым да медицина көллиятен тәмамлап, шәфкать туташлары булып эшли. Әле шатлыклы хәбәребез дә бар: бу атнада Альбинамның никахы. Бәхетләре булсын инде балаларымның, – ди Әлфирә апа.

Кукмара районының Пучинка-Сутер авылында 13 бала үстерүче Роза һәм Владимир Шәйфетдиновлар гаиләсенең язмышын да укучыларга бәян иткән идек. Бәйгедә күреп, алар өчен тагын бер кат сөендек. Кама Тамагының Антоновка авылында яшәүче, республика буенча узган күп кенә экология бәйгесе җиңүчеләре Айгөл һәм Ринат Шәйхайдаровларны да белә укучыларыбыз. Алар 12 ел эчендә 50 меңнән артык агач утыртканнар.

Шәһәр-районнардан килгән гаиләләр янәшәсендә район башлыгы урынбасарлары, башкарма комитет җитәкчеләре, мәдәният бүлегендә эшләүчеләр дә бар иде. Әммә арада җитәкчеләрнең игътибарын күрмәгән гаиләләр дә очрады. Андыйларның берсенең чыгышына бөя бирергә туры килде. Затлы киемнәр, шәп музыкаль чыгыш, бизәлеш булмаса да, бу гаиләдә мәхәббәт яши икән, дидек без. Ир белән хатын бәхеттә йөзәләрмени!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

МУЛЛАГА ДА АШ КИРӘК

Рухи тормыш

Мәдрәсә язмышы кем кулында? «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә узган «түгәрәк өстәл»гә җыелган бер төркем белгеч әнә шул четерекле сорауга җавап эзләде. Максат – бер, авырткан урыннар – уртак. Чишү юлларын тәкъдим иткәндә генә фикерләр бераз аерыла.

Татарга ихтыяҗ зур

Бүген Татарстанда 11 дини белем бирү оешмасы исәпләнә. Аларда 4 меңнән артык шәкерт укый. Татарстандагы мәдрәсәләр Россиядәге иң көчле белем йортларының берсе санала. Әмма алар эшләсен өчен ел саен 50–60 миллион сум чамасы акча кирәк. Уку йортларына кирәкле акчаның яртысын Татарстан Диния нәзарәте бирә. Ислам мәдәнияте һәм белеменә ярдәм фондыннан да акча күчә, кайберләренә меценатлар да ярдәм итә. Әмма бу гына аз, ди белгечләр. Ник дигәндә, бер мәдрәсәне тоту өчен елына 5–10 миллион сум акча кирәк.

Дини белем сагында торган белгечләр бу өлкәдә берләшергә чакыра. Татарның яңарыш чоры саналган XX гасыр башында күпләп мәктәп, мәдрәсәләр ачылган һәм алар, нигездә, милләт язмышына битараф булмаган сәүдәгәр, гади халык күрсәткән матди ярдәм хисабына төзелгән, яшәгән. «Татарлыгыбызны саклап калыйк, дисәк, бу эшне иң элек татар телле кадрлар әзерләүче республика мәдрәсәләренә ярдәм итүдән башларга кирәк». Бу фикер утырышта еш яңгырады.

Ә татар телле дин белгечләренә ихтыяҗ бар. Ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин сүзләренә караганда, татар телле мулла җибәрүләрен сорап, чит төбәкләрдән еш мөрәҗәгать итәләр икән.

– Аларга ихтыяҗ бар. 30 ел эчендә 3000нән артык шәкерт укытып чыгардык. Хәзерге вакытта бездә 400 кеше белем ала. Балтач районында булекчәбез эшли. Шәкертләребезгә 20 укытучы белем бирә, – ди Ильяс хәзрәт.

Ютазы районындагы «Фәнис» мәдрәсәсендә дә конкурс зур. Биредә бер урынга ике кеше дәгъва кыла. Мәдрәсә җитәкчесе, Ютазы районы мөхтәсибәтенең имам-хатыйбы Марат хәзрәт Мәрданшин сүзләренә караганда, 2007 елда төзелгән мәдрәсә иң яңа белем бирү йортларының берсе санала.

– Шуңа да карамастан, җиһазлар шактый тузарга өлгерде инде, мөгаллимнәргә хезмәт хакын арттыру да таләп ителә. Бүген мәдрәсәләрдә укучылар һәм укытучылар – зәкят алучылар рәтендә. Дин мөселман мәгарифе аша тарала. Профессиональ уку йортларына игътибар кирәк, – ди Марат хәзрәт.

Хәзрәткә дә аш кирәк

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе җитәкчесенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин фикеренчә, күпләр мулланы фәрештәгә тиңли. Ә аларның да ашыйсы-эчәсе, киенәсе, тормыш алып барасы бар. Иман йортларына яшьләрнең килергә атлыгып тормавының төп сәбәбен дә шунда күрә ул.

– «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе ябылмасын өчен бюджет елына ким дигәндә 18 миллион сум булырга тиеш. Бездә 50гә якын укытучы, хезмәткәр исәпләнә. Укытучылар 17 мең сум хезмәт хакы ала. Минималь хезмәт хакы күләме бу. Яңа елдан соң ул артырга тиеш. Шуңа күрә укытучыларның хезмәт хакын нәрсә хисабына арттырасы булыр дип, инде бүгеннән үк баш ватабыз. Мәдрәсәдәге укытучы иртәдән кичкә кадәр укыта. Мәчет хәзрәте ашка бара ала әле. Укытучы исә, анда барып, сәдака ала алмый. Көнараләш миңе янга: «Хәзрәт, мин китәм», – дип бәрәр укытучы керә. Аны үгетләү, акча табу бик авыр, – дип сөйләде Рөстәм хәзрәт.

Вазгыятьне азмы-күпме җайга салу өчен быел мәдрәсәдә укуны түләүле итеп тә караганнар. Әлегрәк шәкертләр уку өчен түләүне ихтыяри рәвештә – сәдака итеп кенә керткән булса, хәзер инде бар да килешү төзеп, банк аша эшләнелә. Түләү хакы әллә ни күп түгел, билгеле. Мәдрәсәдә көндезге бүлектә уку – 12 мең сум, кичке бүлектә һәм читтән торып уку исә 10 мең сумга төшә.

– Бу хакта төрле фикерләр ишетергә туры килде. Мәдрәсә хәзрәтләр, абыстайлар, галимнәр, укытучыларны әзерли. Кем өчен? Соңгы кулланучы – халык, без аларны халык өчен әзерлибез. Акча бирегез, дип сорамыйбыз. Укытучы, хәзрәт кирәк икән, уйлагыз. Без укытучылар турында уйлыйбыз, без аларны югалтырга теләмибез, – диде Рөстәм хәзрәт Хәйруллин.

Сорый белеп сорасаң

Четерекле темага фикер алышырга килүчеләр арасында эшмәкәрләр дә бар иде. Дин белгечләренең фикерен алар да куәтли. Ярдәм итәргә дә әзерләр. Сорый белеп сорарга гына кирәк. Россия Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе президенты Айдар Шаһимәрданов бу уңайда бер мисал китерде. Аларның берләшмәсенә кергән бер эшмәкәрдән Республика клиник балалар хастаханәсе ишегалдында урнашачак мәчет төзелешенә матди ярдәм күрсәтүен сораган ул. Тегесе исә артык акчасы юклыгын, әле күптән түгел генә мохтаҗларга 500 мең сум акча күчерүен әйткән.

– Бик хуп гамәл. Әмма бу ихтыяҗлар йортның фасады кебек – тышкы өлеш кенә. Һәр игелекнең нигезе иң элек мәчет, мәдрәсәләргә ярдәм итүдән башланырга тиеш. Хәйрия эшләргә теләгән игәнчене дә әнә шул юнәлешкә кертеп җибәрергә кирәк. Ислам мәгарифен һәм фәнен финанслауны җайга салмасак, яңа Мәрҗанилар, Барудилар булмас, – дип саный Айдар Шаһимәрданов.

Финанслау димәктән, бу эшкә Татарстан Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды да саллы өлеш кертә. Мөселман уку йортларына ярдәм күрсәтү өчен «Мәдрәсәгә игелек кыл» онлайн сервисын булдырган алар. Өч айда 425 мең сум ярдәм җыелган.

Бу саваплы эшкә үз өлешен кертергә теләүчеләр моны сайтка кереп башкара ала: zakyatrt.com.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Язучы сүзе

Җирәнә җиткереп

Подъезд алдына тормыш кимчелекләрен тетеп торабыз шулай. Бер күрше сөйли:

– Беркем үз эшен җиренә җиткереп башкармый хәзер, – ди. – Суыткычымны ремонтка биргән идем, бер атна да эшләмәде, тагын ватылды.

– Хатын башы авыртып врачка барды, мин биләмә чыдый алмыйча бардым. Икебез дә фәлән меңлек дару төяп кайттык, – дип сөйли икенче күрше. – Кайткач караган идек, икебезгә дә бер үк төрле дарулар язып биргәннәр.

– Нинди дарулар ул? – дип кызыксына өченче күрше, теге санап күрсәткәч, телен шартлатып куя. – Бәтәч, миңа да шуларны биреп кайтардылар бит. Эч авырткаччан.

Шул рәвешле бик камил генә әңгәмәләшеп торганда, подъезд янына сәпит белән курьер килеп туктый. Йорт, подъезд санын белешә дә ишек кыңгыравына баса. Минем фатирныкына.

– Сез миңа килгәнсез бит, – дим моңа. – Нәрсә китердегез?

– Сез Фәлән Фәләновамы? – дип бөтенләй таныш түгел исемне атый бу. – Фәләненче фатирдан?

– Фатиры дөрес, – мин әйтәм. – Тик мин Фәлән Фәләнова түгел. Бу фатирда андый кеше яшәми.

– Монда шулай дип язылган.

– Яхшы. Китапларны алып килдегезме?

– Юк, дәфтәрләр.

– Мин китапларга заказ биргән идем, димәк, ялгышкансыз.

– Ялгышмадым, – ди курьер, үз хаклыгына ышанып һәм мине дә ышандырырга тырышып. – Шундый-шундый йорт, шундый фатир.

– Тик мин дәфтәр сорамадым.

– Димәк, сорагансыз, – ди курьер. – Менә бит заказыгыз.

– Анда бит хатын-кыз фамилиясе. Ә мин – ир кеше. Азрак аерма сизәсезме?

Күршеләр көлешеп куя. Курьер җитдиләнә.

– Бәлки, хатыныгыз заказ биргәндер.

– Хатынның исеме бүтән.

– Бәлки, кызыгыздыр?

– Кызның фамилиясе бүтән... – Аптыраганнан әйтәм инде моны. Исеме дә, фамилиясе дә туры килми теге кешенең. Тик курьер бирешергә ашыкмый:

– Квартирант тотмыйсызмы?

– Юк.

– Ә урамы нинди соң? – дип сүзгә кушыла күршеләрнең берсе. Курьер кулындагы капка күз йөртеп ала:

– Ә бу нинди урам?

Урам исемен ялгышуын белгәч тә курьер китәргә ашыкмый:

– Сез китапларга заказ биргәнсез бит, – дип миңа төбәлә. – Бәлки, дәфтәрләр дә кирәктер?

Мин баш чайкыйм. Ул баш кага:

– Әйбәт дәфтәрләр, акция белән.

Тәрәзәдән хатынның тавышы ишетелә:

– Нишләп торасың анда, әшеңә соңлыйсың бит.

Мин тиз генә өйдән урап чыгам. Такси чакырам. Такси биш минуттан килергә тиеш. Үн минут уза. Яңаны чакырам. Ул бер сәгатьтән генә бушаячак икән. Өченче номерны җыям. Ул өч минуттан килергә вәгъдә бирә дә унбиш минуттан килеп җитә. Машинага кереп утыруга телефон шалтырый:

– Такси чакырган идегезме?

– Гафу итегез, биш минут узды, ә сез килмәдегез.

Трубканы куеп, каешны элүкерүгә тагын телефон:

– Такси чакырган идегез...

Мин сүзне әзәм, тик шундук тагын шалтырый:

– Сезне шундый-шундый автомобиль көтә, – ди робот тавышы.

Мин телефонны сүндереп куям да җайлап урнашам. Юкка гына икән. Подъезд алдыннан кузгалып, берничә адым китүгә машина сүнә. Таксист озак кына ачкычын боргалый. Мин көтәм. Ахырда аккумуляторы утыра. Ул зарланып куя:

– Әр-яңа аккумулятор бит! Машинаны да яңа гына сервиска кертеп чыгарган идем.

Мин, гафу үтенеп, аны ташлап китәм. Үзебезнең йорт янында торган таксины күреп йөгерә башлыйм. Яңа гына сатып алынган туфлиның укчәсе чыгып оча. Мин асфальтка барып төшәм. Әйбәтлеккә кия торган кәчтүмнең җиңе умырылып төшә. Торып басам да, туфлиларны кулга тотып, тагын йөгерергә керешәм. Такси кузгалып китә. Мин аның артыннан йөгерәм. Туктый. Кереп утырам.

– Зинһар, тизрәк. Эшкә соңга калдым.

Ул артыгын сөйләнмичә генә газга баса. Мин киемнәремне тәртипкә китерергә тырышам.

– Килеп җиттек.

Мин түлим дә төшәм. Ул кузгалып китә. Шайтан алгыры! Әллә кайда ташлап калдырган бит. Димәк, мин чакырган такси булмаган, дип нәтиҗә ясыйм. Тукталышка чыгып басам. Кирәкле автобус биш минут саен йөри икән. Шулай дип язылган. Ярты сәгать көткәч, теге язуны тагын бер кат барып карыйм. Дөрес. Ниһаять, автобус килә. Кереп утырам. Акчамны түлим. Ике-өч тукталыш үткәч, йөртүче сөрән сала:

– Хөрмәтле пассажирлар, техник сәбәпләр аркасында гаражга кадәр генә барабыз.

Эшкә соңардым. Киемнәрне булса да алыштырып чыгарга кирәк. Мин үзебезнең йорт янында төшеп калам. Подъезд алдында ирләр гәпләшеп тора. Алар янына житүгә, теге курьер килеп җитә. Мине күргәч, елмаеп җибәрә:

– Карагыз әле, бәлки, сез заказ биргәнсездер? – ди, үтенечле күзләрен миңа төбәп. – Теге адресга да булмады бит.

Мин аңа ачулы караш ташлыйм да йомшара төшәм. Йончыган, бахыр. Бу да үзем кебек бер бәндә бит инде: башкалар үз эшен җиренә җиткереп башкармаган өчен, үз эшен җиренә җиткереп башкара алмыйча йөри.

– Китерегез, – дим.

– Мәгез, – дип балкый ул. – Фәлән сум.

Мин алам. Түлим. Фатирга кергәч, балконга чыгам. Урамга күз салам. Кешеләр ашыгалар. Күзләренә ак-кара күренми. Юк, бу дәрәҗәдә ашыгып эшләп тә, яшәп тә булмый торгандыр. Болар да нәкъ минем шикелле кешеләрдер. Бүтәннәр үз эшен җиренә җиткереп башкармаган өчен тормыш тирәли әйләнеп йөрүчеләр...

Марат КӘБИРОВ

И туган тел, и матур тел...

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ТАТАР

Казан

ЯШӘҮ ЯМЕ

Авылда телне дә, гореф-гадәтләрне дә саклап була әле, шәһәр генә барысын да кабып йотарга әзер, дигән сүзләрне кемнең генә әйткәне яки ишеткәне юк икән. Бер караганда, дөрес тә кебек, әмма күңел биреп тырышканда, хәл итә алмаслык мәсьәлә түгел бу. Казанда яшәүче Сәфәровлар гаиләсе белән без нәкъ шул хакта сөйләштек.

Остаз киңәше

Сәфәровлар – ил-көн игътибары үзәгендә яши торган гаилә. Күп еллар газетабызның баш мөхәррире булып эшләгән Миңназыйм Мәүлет улы бүген Татарстан дәүләт радио-телевидение комитетында милли тапшырулар хезмәтен җитәкли. Шуңа күрә дә ул бу мәсьәләгә бигрәк тә җитди карый: беренче чиратта үзебез үрнәк күрсәтергә тиешбез дип фикер йөртә.

– Без өч буын – балалар, оныклар белән һәр көн диярлек даими аралашып яшибез, – дип башлады ул сүзен. – Дүртенче буын – әбиебез авылда. Кышларын безгә дә килеп тора, үзебез дә еш кайтабыз. Балаларны, оныкларны үстергәндә барыбызга да телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу өчен зур тырышлык күрсәтергә туры килде. Сиксәненче елларда шәһәрдә яши башлаган кеше хәтерлидер: транспортта барганда «культурный» апалар «ведите себя прилично» дип шелтә белдерәләр иде. Күрәсең, ана телендә сөйләшү хулиганлык билгесе дип кабул ителгәндер инде. Әлбәттә, бүген андый күренешләр күзәтелми. Әмма, ни кызганыч, башка каршылыклар бар.

Мин хәтерлим әле: кызыбыз Гөлназны беренче көнне балалар бакчасыннан алырга барганда, тәрбияче чыкты. Күзләре маңгаена менгән. «Ул бит русча бер сүз дә белми», – ди. «Өйрәтегез», – дидем. Берничә көннән үк, өйгә кайткач, русча сүзләр әйтә башлады бу. Үзебезчә бик сөендек инде. Русча да белергә кирәк бит. Шул вакытта баш мөхәрриребез Исмәгыйль Шәрәфиев, мин ул вакытта «Татарстан яшьләре»ндә эшли идем, бер киңәш бирде: «Миңназыйм, безнең хатаны кабатлама. Без дә сезнең кебек сөенеп, русчалары камил булсын дип, балалар белән русча сөйләшә башлаган идек. Шул чакта бик тә хаталанганбыз. Соңрак кына аңладык. Тел онытылмасын өчен, алар өйдә татарча сөйләшергә тиешләр», – диде.

Гаилә һәм мәктәп

– Без хәзер күп әйберне мәктәпкә сылтап калдырырга тырышабыз, – дип сүзгә кушылды татар-инглиз гимназиясендә күп еллар татар теле һәм әдәбиятын укытып, лаеклы ялга чыккан Резидә ханым. – Күпләр: «Ата-аналарның вакыты юк, мәктәптә өйрәнсеннәр», – дигән фикердә. Әмма бүген мәктәп, ни кызганыч, тәрбия урыны түгел. Хәзер укытучылар тәрбия эше белән шөгыльләнергә өлгерми. Аларның вакытын документлар тутыру, кәгазь эшләре белән бик чикләделәр. Сүз дә юк, нәтиҗәле эшләргә кирәк. Әмма, нишлисең, шартлар шундыйрак. Мин үзем, лаеклы ялга чыгу сәбәпле, мәктәптән киттем. Оныкларым белән мәш киләм: озатам, каршы алам. Шунда әби-бабайларга шаккатам. Балалары белән телне вата-җимерә, үзара русча сөйләшәләр. Ни кушымчалары, ни килешләре дөрес түгел. Бу хәл икеләтә зыян китерә бит. Беренчедән, оныкларына туган телне өйрәтә алмыйлар, икенчедән, рус теле культурасын да юкка чыгаралар. Әлбәттә, бар нәрсәне дә җәмгыятькә сылтап калдыру җиңел. Әмма каршылыклар гел туып тора бит. Шушы каршылыкка каршы тора алырлык көч булырга тиеш, минемчә.

Кызлары Айсылуның ире Нияз бу җәһәттән үз фикерен җиткерде:

– Бу көч гаилә булырга тиеш инде, чөнки бала өчен әти-әнидән, әби-бабайдан да тәҗрибәлерәк кеше юк. Дөрес, телефон, телевизор, гаджетларга каршы тору авырлашты. Әмма бу эшне гаиләдән башламасак, без бернигә дә ирешә алмаячакбыз. Гаилә ул терәк, җанга җылылык бирә торган урын булырга тиеш.

Гаилә көче дигәннән, Гөлназ да үз тормышыннан мисал китерде.

– Ирем Ленар өйләнешкәнче рус телендә генә сөйләшә иде. Дөрес әйтмәм дип курка иде ул. Минемчә, андый кешене җиңелчә формада гына төзәтә белергә кирәк. Тырышлыгым бушка китмәде. Хәзер ирем иркен сөйләшә. Аңлый. Җавап бирә, сөйләшүгә кушылып китә ала.

Ана теле

– Ана теле турында уйланганда күңелдә күп сораулар туа, – дип дәвам итте сүзен Гөлназ. – Кеше ни өчен туган телендә сөйләшми? Оялмы ул? Татарча белү кирәкми дип уйлыймы? Күпме җавап эзләп карасам да, аңлап бетерә алмыйм. Кайберәүләрнең турыдан-туры: «Нәрсәгә кирәк ул татар теле?» – дип әйткәннәре дә булды. Мондый сорауны ничек бирергә була инде?! Туган тел – ана теле. Димәк, нәрсәгә кирәк ул миңа әни дип, иң якын кешеңнән йөз чөергән кебек килеп чыга бит.

– Әмма монда тагын бер әйбер бар, – дип фикерне киңәйтебрәк җибәрде әтиләре Миңназыйм. – Татарда гомер-гомергә, русча яхшы белсәң, син кеше буласың, дигән ышаныч яшәп килә. «Татар теле нәрсә инде ул? Үзебез дә җәфа чиктек», – дип зарланганнарын бик күп ишеткәнем булды. Бу бит бөтенләй ялгыш фикер. Беренчедән, татар теле төп тел булган кешеләр дә менә дигән зур урыннарда эшли. Икенчедән, туган телне яхшы белү рус телен камил өйрәнергә комачауламый бит. Әле алар янында инглиз һәм башка телләрне дә белү бик яхшы булыр иде.

Күп тел белү ни бирә?

Бу сорауга татар телен дә, рус телен дә камил белгән, үзенә кирәклесен инглиз телендә дә сөйләшә алган Гөлназ җавап бирде.

– Кешенең башы компьютер сыман. Бик күп мәгълүматларны истә калдыра. Шуңа күрә дә без бик күп телләр өйрәнә алабыз. Бу бит безнең тормышка карашыбызны киңәйтә. Әлбәттә инде, полиглот кешеләр дә бар. Мәсәлән, минем дус кызым җиде тел белә, иркен аралаша. Әмма без дә үзебезгә кирәклесен өйрәнә алабыз бит. Бу фикерне мин улым Айданга да сеңдерергә омтылам. Ул әлегә татарча, русча, инглизчә иркен аралаша.

Әнисенең бу сүзләрен улы да җөпләде. Ничек өйрәнүен сөйләп алды.

– Кечкенә чагымда бабай миңа татарча төрле китаплар бүләк итә иде, – диде ул. – Рус телендә булса, аны татарчага тәрҗемә итә. Рәсемнәр астына сүзләрне язып куя. Аңламаганнарын әнидән дә, дәү әнидән дә сорый идем. Әни хәтта рульдә булганда да, миннән сүзләрнең тәрҗемәсен сорап бара. Бер минутны да әрәм итмибез.

Мондый тырышлыкның файдасы тими калмый, әлбәттә. Инде өч яшь ярым чагында ук Айдан Галиәсгар Камалның «Беренче театр» спектаклендә Хәмзә бай ролен башкара. Энекәшләре – Айсылу апасының уллары Азамат белән Данияр онытылып китеп русча сөйләшә башласалар, аларны да тиз туктата, татарча сөйләшергә куша.

Сәфәровлар гаиләсеннән киңәшләр

◆Балалар сөйләшсеннәр өчен, туган телне, беренчедән, югары дәрәҗәгә җиткереп, бренд рәвешенә китерергә кирәк. Икенчедән, Татарстан Рәисенең барлык чараларны да ике телдә алып барырга дигән боерыгы бар һәм без шулай эшлибез дә. Кайбер башка өлкәләрдә дә боерык формасын куллану зыян итмәс иде.
◆Без, гаиләдә татарча сөйләшергә кирәк, дигән язылмаган законга буйсынырга, таянырга тиеш.
◆Балаларны, кирәк-кирәк, дип кенә өйрәтергә түгел, күп нәрсәне уен формасында алып бару отышлы. Күп вакытта урыннарны алмашу файдалы, ягъни мәсәлән, оныклар әти-әни яки әби-бабай ролендә безне татарча сөйләшергә өйрәтәләр.
◆Күп кенә әти-әниләр: «Минем балам татарча шундый әйбәт сөйләшә иде. Садикка китү белән онытты», – дип, җаваплылыкны үз өсләреннән төшерергә ярата. Моның белән килешергә, үз-үзеңне ышандырырга һич кенә дә ярамый.
◆Телләр белү ул – баш миен хәрәкәттә тоту. Димәк, стресска урын юк, яшәвеңнең мәгънәсе, яме бар дигән сүз.

Кияү пәрәмәче

Камырга 0,5 литр җылымса су, 100 грамм атланмай, ярты чәй кашыгы тоз, бер чәй кашыгы шикәр комы, 2–3 аш кашыгы үсемлек мае кирәк. Токмачныкыннан йомшаграк итеп камыр басасы, 2–3 мм калынлыгында җәймә җәясе. Диаметры 8–9 см булган чынаяк яки стакан белән түгәрәкләр ясап, кырыйларын бөгеп, тартолетка сыман савытлар ясыйсы. Шул камыр савытларына алдан шулпа кушып пешерелгән тарттырылган ит салып, үсемлек мае салынган табада мичтә кызарганчы тотасы. Ипи мичендә пешкән пәрәмәчнең тәме икенче була. Тәмле булсын!

Сәхифәне Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде. Фото – гаилә архивыннан

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 14047 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 330

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+